ӘҢГӘМӘ
«Халкыбызга чал тарихыбызны күрсәтергә тиешбез»
→ 4 БИТ

ӘДӘП ВӘ ӘХЛАК
Раббыбыз каршындагы әдәпләр
→ 7 БИТ

САБЫЙГА
Нух галәйһиссәлам көймәсе
→ 9 БИТ

ӘДӘБИ СӘХИФӘ
Җиләкле тау сере
→ 14 БИТ

**ФЕВРАЛЬ, 2022**
№ 02 (319)

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

җөмәдәл-ахыр – раҗәб, 1443

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+



**Пәйгамбәребезнең хәдисендә Мигъраҗ вакыйгасының фазыйләтләре ассызыклана: «Мигъраҗ вакытында, Аллаһының рәхмәте буларак, өч нәрсә бүләк ителде: биш вакыт намаз, «Әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы аятьләре һәм Аллаһыга ширек кылмаучы кешеләргә гафу кылыну мөмкинлегенең барлыгы» (Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).**

→ ДӘВАМЫ 6 НЧЫ БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!



Фото: yandex.ru

# Чираттагы «Затлы мәҗлес» узды

**10 нчы февральдә «Туган авылым» милли-туристик комплексында Казан мөслимәләре чираттагы «Затлы мәҗлес»кә җыелды. Әлеге чарага илледән артык хатын-кыз килде.**

Ике сәгатьтән артык дәвам иткән очрашуда алар хиҗаб киюнең фазыйләтләре хакында фикер алышты. Кичә интерактив уеннар һәм ихлас аралашу белән үрелеп барды, катнашучылар хиҗабның яулык кына түгел, Аллаһының әмере, хатын-кызның яшәү рәвеше булуын ассызыклап үттеләр.

Утырыш Коръән аятьләре уку белән башланып китте. Аннары Нәзарәтнең социаль үсеш бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимирова тарихка кыскача күзәтү ясады: татар хатын-кызлары киеме традициясе турында сөйләде һәм хиҗабның әбиләребезнең гардеробында аерылгысыз өлеш булуын аңлатты. Моңа мисал итеп ул Каюм Насыйри һәм Карл Фукс кебек галимнәрнең фәнни хезмәтләреннән мисаллар китерде.

Кичәне интерактив уеннар баетты. Кызлар MUSLIMMOL яшьләр хәрәкәте тарафыннан оештырылган «Надевая платок…» бәйгесе өчен иҗат ителгән шигырьләрен укыдылар, хиҗаб кию тарихы белән уртаклаштылар, фикер алыштылар, мастер-класста хиҗаб өчен бизәнү әйберләре ясадылар.

«Затлы мәҗлес» проектының төп максаты – бергә җыелып, дин турында ачыктан-ачык сөйләшүләр алып барудан гыйбарәт. Очрашуларда Исламның матурлыгы, хатын-кызның нәфислеге һәм күңел дөньясы, Коръән, дин, фикһ мәсьәләләре, татар халкының хатын-кызлар белән бәйле традицияләренә багышланган темаларга сөйләшүләр алып барыла.

# «Гаилә» мәчетендә гаиләләр өчен ышаныч телефоны эшли башлады

**Казанның «Гаилә» мәчетендә яңа проект – гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтү буенча Рәсәйкүләм ышаныч телефоны эшли башлады. 8-800-222-05-62 федераль номерына шалтырату – сөйләшүнең дәвамлылыгына карамастан, һәрбер мобиль яки стационар телефоннан бушлай. Аралашу аноним һәм конфиденциаль рәвештә алып барыла. Телефон Рәсәй территориясендә эшли, аңа илнең теләсә кайсы почмагыннан шалтыратырга мөмкин.**




Фото: dumrt.ru

Ышаныч телефоны буенча консультацияне «Гаилә» мәчете каршында эшли торган «Адәм белән Һава» исемле Гаилә төзү һәм аны саклау үзәге белгечләре бирәчәк. Гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтү хезмәте ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрдә кыенлыкларны чишәргә, балалар белән мөнәсәбәтләрне җайларга, кризис халәтеннән чыгу өчен шәхси һәм рухи ресурсларны эшкә җигәргә ярдәм итәчәк. Ышаныч телефоны эшчәнлеге кешеләрдә хисси яктан төшенлеккә бирелүне, үз-үзеңә кул салу, аерылышу очракларын булдырмый калуга, шулай ук җәмгыятьтә гаилә институтын ныгытуга һәм татар-мөселман традицияләрен саклап калуга юнәлдерелгән.

# «Ислам. Беренче адымнар» проектының 9 нчы сезоны ачык!

**12 нче мартта Татарстан мөфтиятенең халык арасында зур популярлык казанган проекты – «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбе үз эшен кабат башлап җибәрә. Хәзерге вакытта 9 нчы сезонда белем алырга теләүчеләрдән гаризалар кабул ителә.**



Фото: dumrt.ru

Проект 4 ел дәвамында мәчет каршындагы курсларга йөрергә вакыты булмаган дин кардәшләргә гыйбадәт нигезләрен үти башларга мөмкинлек бирү өчен махсус гамәлгә ашырыла. «Ислам. Беренче адымнар» проекты – кыска вакыт эчендә Ислам нигезләрен үзләштереп, намаз укырга өйрәнүне максат иткән чара.

Ул мөфтият тарафыннан 2018 елда дәгъват эшчәнлеге кысаларында тормышка ашырыла башлады.

Дәресләр атнага бер тапкыр шимбә көннәрендә 8.00дән 13.00гә кадәр Казанның Галиев мәчетендә (Тукай ур., 40) үткәреләчәк. Барлыгы 8 дәрес үткәрү күздә тотыла: «Кереш дәрес» (терминология, Ислам динендә рөхсәт ителгән һәм тыелган гамәлләр, тәһарәт), «Намаз дәресе» (намаз уку тәртибе, намазда укыла торган сүрәләр һәм догалар), «Исламның төп баганалары» (ураза, зәкят, хаҗ), «Гакыйдә дәресе» (иманның төп баганалары).

Барлык дәресләр дә – бушлай, укыту татар һәм рус телләрендә алып барыла. Дәресләрне үткәрү планына шулай ук уку өчен кирәк булган материаллар тарату да кертелгән.

**Бу курсларга +7 (843) 237-86-18 телефонына шалтыратып язылырга мөмкин.**

# Татарстан мөфтие хоккей буенча хәйрия матчында уйнады


Фото: dumrt.ru

**15 нче февральдә Казанда хәрәкәт функцияләре чикле балалар өчен «Хоккей – һәркемгә» дип исемләнгән хәйрия матчы узды.**

Ярышлар ике команда – «Метеор» һәм «Вымпел» командалары арасында үтте, һәр уенчыны бозда «штурманнар» – «Ак Барс» хоккей командасы уенчылары Дмитрий Юдин, Александр Бурмистров һәм Төнге Хоккей Лигасы командасы хоккейчылары хәрәкәтләндереп йөрде. Чараны Төнге Хоккей Лигасының Татарстан Республикасындагы вәкиллеге һәм «Даже если» ивент-агентлыгы оештырды. «Хоккей – һәркемгә» акциясе кысаларында Казаннан һәм Түбән Камадан сәламәтлеге чикләнгән балалар командалары катнашты.

Хәйрия матчында шулай ук мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, Духосошественский храмы настоятеле Алексий Чубаков, «Ак Барс» хоккей клубы генераль менеджеры Марат Вәлиуллин һәм башкалар катнашты. Бу ярышны күзәтеп утырган ата-аналар үз балаларына көч биреп торды.

Камил хәзрәт әлеге хәйрия ярышында Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды тәрбиясендә булган Әмир Фәтхлисламов белән бергә уйнады. Бу балага хәйрия фонды инвалид коляскасы сатып алуда матди ярдәм күрсәткән иде. Әмиргә 14 яшь һәм анда ДЦП. Ул «Хәят» үзәгенә йөри, ислам нигезләрен һәм кул эшләрен үзләштерә. Ул балалар белән аралашырга ярата. Әмирнең әти-әнисе Татарстан мөфтиенә, «Зәкят» фонды хезмәткәрләренә һәм следж-хоккейны оештыручыларга рәхмәтләрен белдерде. «Зәкят» фонды эшчеләре безне гел елмаеп, матур итеп каршы алалар, шулай ук озатып калалар», – диде аның әнисе.

Үзенчәлекле балалар белән мондый проект 2018 елдан гамәлгә ашырыла, бу вакыт эчендә анда 100дән артык бала катнашты. 2019 елда «Хоккей – һәркемгә» Түбән Новгородта «Event-прорыв» премиясе белән бүләкләнде һәм «Иң яхшы социаль проект» номинациясендә җиңүче булды.

Мондый ярышларның төп максаты – балаларга үзләрен хоккейчылар ролендә тоярга мөмкинлек бирү. Аларның күбесе беренче тапкыр бозга чыга.

Бу игелекле проектның төп дәвамы булып ТР адаптив спортын үстерү үзәген төзү булды, аның базасында Татарстанда беренче булган «Ак Барс следж» балалар командасы формалаштырылды.

# «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗларга азык-төлек җыелмалары тарата

**Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗларны ризык белән тәэмин итүне дәвам итә.**



Фото: dumrt.ru

9 нчы февральдә 20 мохтаҗ гаиләгә азык-төлек җыелмалары таратылды. Хәйрия фондыннан әлеге ярдәмне бер ялгызы балалар үстерүче аналар, күп балалы гаиләләр, ялгыз пенсионерлар, инвалид бала тәрбияләүчеләр алды. Азык-төлек җыелмасында он, ярмалар, көнбагыш мае, консервалар, шикәр һәм татлы ризыклар, макарон һәм чәй бар.

Авыручылар саны көчәйгән вәзгыятьтә ярдәм итүнең мөһимлеген билгеләп, «Зәкят» фондында социаль яктан мохтаҗ булучыларның артуын билгеләп үттеләр; коронавирус пандемиясе чорында күп гаиләләр эш югалту, даруларга акча күп сарыф итү сәбәпле, азык-төлек җыелмаларын күбрәк мохтаҗларга тарату таләп ителә.

Акча кергән саен ТР МДНнең «Зәкят» хәйрия фонды азык-төлек таратуны оештыра.

**Бу изге гамәлдә катнашасыгыз килсә, Сбербанк картасына 2202 2021 3911 9295 (Зиля Ириковна И. – «Зәкят» фонды хезмәткәре) акча күчерә аласыз.**

**Раббыбыз изге эшләрегезне кабуллардан кылсын!**

**dumrt.ru** сайтыннан

## Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин:

# «Халкыбызга чал тарихыбызны күрсәтергә тиешбез»

**2022 ел Рәсәебездә зур вакыйга, истәлекле дата – болгар бабаларыбызның Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүенә 1100 ел. Шулай ук быел тагы бер мөһим вакыйга – башкалабызның Казансу елгасы ярында Җәмигъ мәчетенең төзелә башлавы көтелә. Мәчеткә нигез салыну, Аллаһы боерса, нәкъ менә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтү көннәрендә тормышка ашырылырга тиеш. Төзергә ниятләнгән мәчет хакында һәм истәлекле дата билгеләп үтүнең мөһимлеге турында Казан шәһәренең Совет районы мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин белән сөйләштек.**


Фото: yandex.ru

**– Хәзрәт, әссәләмү галәйкүм. Быел Татарстаныбызда зур вакыйга – Болгар бабаларыбызның Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы билгеләп үтелә. Сезнеңчә, халкыбыз өчен бу чара, тарихыбызны искә төшерү нинди роль уйнаячак?**

– Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Әлбәттә, беренчедән, әлеге вакыйга халкыбызның үз тарихына игътибар бирүенә этәрер дип өметләнәм. Икенчедән, меңләгән, миллионлаган татар халкына динебезне, гореф-гадәтләребезне өйрәнә, аның белән кызыксына башлавына бер этәргеч булуына өмет баглыйм. Сүз дә юк, бу чараны үткәргәндә без булдыра алганча халкыбызга үзебезнең чал тарихыбызны күрсәтергә, аның хакындагы мәгълүматны һәрбер кешегә дә җиткерер өчен тырышырга тиеш.

**– Бездән соң килгән буын Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең тарихын истә тотсын өчен без нәрсә эшли алабыз?**

– Безнең татар халкы Ислам динен кабул иткән урын турында, ул вакыйга хакында истә тотсын өчен, әле үз вакытында Тәлгать хәзрәт Таҗетдин тарафыннан торгызылып җибәрелгән шушы күркәм мәрасимне, күркәм йоланы дәвам итәргә кирәк. Анда бөтен милләтләр катнашканда, бу – татар халкының рәсми рәвештә Ислам дине кабул иткән урыны, дип тәкърарланырга тиеш, дип саныйм. Бу урын халыкның фәкать җыелышып, ашап-эчеп, ял итеп китү урыны түгел, ә бөтен Рәсәй җирлегендә, иң беренче булып Ислам динен кабул иткән халык менә монда яшәгән, нәкъ шушы урында Ислам динен кабул иткәннәр, дип фикерләнергә тиеш. Бу безнең тарихи урын, Ислам динен кабул иткән җир икәнлеген без онытмыйча һәр ел саен шушы изге гамәлне истә тотып, Болгар җирендә җыелышуыбызның бер дә зыяны булыр дип уйламыйм. Киресенчә, файдасы гына булыр дип саныйм.

**– Соңгы вакытта Казансу яр буенда мәчет төзелүнең планлаштырылуы хакында хәбәрләр ишетәбез. Ничек уйлыйсыз, Казанга, гомумән Татарстаныбызга мондый зур мәчет кирәкме?**

– Бу зур мәчетнең төзелүе – безнең милләт халкының соңгы 30-35 ел буе кылган догасының нәтиҗәсе ул. Иртәме соңмы ул төзеләчәк һәм милләтебезнең яңа тарихи һәйкәленә әвереләчәк дип иманам. Аның Казаныбызның мөкатдәс шәһәр икәнлегенең бер бәясе, бер дәлиле булып торуына ышанып яшим.

**– Башка мәчетләрдән үзгә итеп төзелергә ниятләнгән бу бина – яңа мәчет, сезнеңчә нинди булырга тиеш? (Динебез нормаларыннан читкә китмәсен өчен)**

– Әлбәттә, бу мәчет бөтен яктан да бик нәфис булырга тиеш. Аның төзелешендә архитектура ягыннан да, функциональ яктан, инженерия ягыннан да иң алдынгы алымнар кулланылырга тиеш. Сүз дә юк, бу вакытта шәригать таләпләреннән чыгу тиеш түгел һәм шул ук вакытта төзелеш безнең хәзерге фәнни һәм техник прогрессның соңгы иң алдынгы нәтиҗәләрен кулланып гамәлгә ашырылырга тиеш, дип саныйм.

**– Шул ук вакытта, сезнеңчә, әлеге мәчет нинди булмаска тиеш?**

– Бу мәчет, гомумән, нindидер бер бәхәсләр урынына әйләнмәскә тиеш, ягъни бездә – дин әһелләрендә, мөселман кардәшләребездә мәчеткә кагылышлы бәхәс чыга калса да, шушы юлдан Аллаһы Тәгалә сакласын дип, дога кылырга һәм үзебезгә дә моннан сакланырга кирәк. Шушы мәчет бәхәсләрдән, гаугадан ерак булса иде. Бу мәчетнең татар халкының яңа һәм мәңгелеккә таба үрелгән бер милли маякларының берсе булып китүенә өметләнәм.

Әңгәмәне **Айсылу Юлдашева** оештырды

МӨФТИ КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИННЫҢ МӘКАЛӘЛӘР ЦИКЛЫ

## «ПӘЙГАМБӘРЛӘР КЫЙССАСЫ»

ДИП АТАЛГАН ЯЗМАЛАР СЕРИЯСЕ



Фото: dumrt.ru

# ТАУ КУЫШЫ КЕШЕЛӘРЕ КЫЙССАСЫ

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Бу хакта Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

*«[Расүлем! Күзләре ачык булганга күрә һәм уңга-сулга карап торганнары өчен] Син аларны уяу дип санарсың, әмма алар йоклыйлар. Без аларны [туфракның черетүеннән саклау өчен] әле уң якка, әле сул якка әйләндерә идек. Этләре дә алда алгы аякларын сузып ята иде. Әгәр аларны [чәчләре, тырнаклары җиткән хәлдә] күрә алган булсаң, һичшиксез, алардан йөз чөерер һәм алар аркасында курку эчендә булыр идең».*

*«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:18*

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә аларны мәгарәдә йоклаткан һәм Үзе үк, үлгәннән соң терелү булуны дәлил итеп, йокыдан уяткан.

Мәгарәдә яшәүчеләр уянгач, Дикьянусның гаскәрләре әле һаман да аларны эзәрлеклидер, дип уйлаганнар. Ләкин тамаклары ачыкканга күрә, бер иптәшләрен азык эзләү өчен шәһәргә җибәрергә мәҗбүр булганнар. Туган шәһәренә килеп җиткәч, егет таң калган: урамнар һәм йортлар танымаслык булып үзгәргән! Хәтта кесәсендә булган акчасы да күп еллар элек әйләнештән чыккан булуын аңлаган ул. Егет аңына аермачык булып шундый уй килгән: йоклап киткәннән бирле берничә йөз ел үткән, явыз Дикьянус күптән вафат, ә хәзерге патша иман китерә һәм калган халык та үз динен иркен рәвештә тота ала икән.

Әлеге тарихны бар кылып, Аллаһы Тәгалә кешеләргә Үзенең үлеләрне яңадан терелтү вәгъдәсен хаклык итеп кабул итәргә мөмкинлек биргән. Риваятьләрнең берсендә, Дикьянус үлгәннән соң, бик күп патшалар алмашынды, дип хәбәр ителә. Ахыр чиктә, бу илнең идарәчесе итеп мәрхәмәтле кеше куела. Ул, кешеләр үлгәннән соң, алар җаны белән дә, тәне белән дә кубарылачакларына ышанган. Әмма җәмгыятьнең бер өлеше тән түгел, бары җан гына кубарылачак дип санаган. Әлбәттә, мондый карашлар халык арасында фетнә чыгуга сәбәп булган. Аны юкка чыгару өчен, мөселман булган җитәкче Аллаһы Тәгаләдән аңа һәм аның тарафдарларына хакыйкатькә ишарәләгән берәр вакыйга күрсәтүен үтенгән: «Ий Раббым! Син барлыкка килгән каршылыкларны күрәсең. Кешеләргә хакыйкать барып җитсен өчен, безгә аңлатучы билгеләреңне һәм дәлилләреңне җибәрсәң идең».

Аллаһы Тәгалә бу игелекле колның ялваруын кабул иткән һәм Кыямәт көненең һичшиксез булачагы һәм үлгәннәрнең кабаттан кубарылачакларын күрсәтү билгесе буларак, Раббыбыз өч йөз тугыз елдан соң әлеге яшь егетләрне уяткан.

*«Шулай итеп, Без алардан хәбәрдар иттек, Аллаһының [бөтен кешеләрне терелтү] вәгъдәсе [дә] хак булганын, Сәгатьнең җитүендә шөбһә булмаганын [кешеләр] белсеннәр...».*

*«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:21*

Моңа бер дә шикләнмәгез, хөрмәтле дин кардәшләрем!

# ҺАБИЛ БЕЛӘН КАБИЛ КЫЙССАСЫ

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдәге «Әл-Маидә» сүрәсенең түбәндәге аятендә болай дип әйтә:

*«Аларга Адәмнең [Һабил белән Кабил исемле] ике улының хәбәрен хак [бер бәян] белән укы ...».*

*«Әл-Маидә / Табын», 5:27*


Әлеге сүрәдә бар мөэминнәргә үгет-нәсыйхәт итеп, кешелек тарихыда иң фаҗигале сәхифәләренең берсе хакында бәян ителә. Раббыбызның әмеренә буйсынып Һабил һәм Кабил турында без дә искә төшерик...

Адәм галәйһиссәлам һәм Хәвва радыяллаһу ганһә җәннәттә яшәгәннәр. Әмма тыелган агачның җимешен татып карагач, алар җиргә – Хәвва радыяллаһу ганһә Җиддәгә, ә Адәм галәйһиссәлам Һиндстан җиренә җибәрелә. Кылган ялгышларына ихластан тәүбә итеп һәм елап, алар Аллаһыдан кичерүен сорап ялварганнар. Кодрәтле һәм Гафу итүче Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә аларның тәүбәләрен кабул иткән һәм аларга Мәккә янындагы Гарәфәт үзәнендә очрашырга рөхсәт биргән. Бераздан Аллаһы Тәгалә аларга балалар да бүләк иткән һәм шул рәвешле кешелек дөньясы үрчи башлаган.

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә Адәм галәйһиссәлам белән Хәвва радыяллаһу ганһәгә күп балалар насыйп иткән. Тапкан саен Хәвва радыяллаһу ганһә дөньяга игезәк балалар тудырган. Аларның берсе һәрчак кыз бала, икенчесе ир бала булган. Шулай итеп ул егерме пар балага тормыш биргән, бары тик Шис галәйһисәлләм генә берүзе туган.

*(Дәвамы киләсе санда)*

# Пәйгамбәребезнең бөек сәяхәте


Фото: yandex.com

**Галәмнәрнең Раббысы булган Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкераналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребезгә салават, сәламнәребез булсын.**

Раббыбыз Коръәни Кәримдә:

*«Аятьләребездән кайберләрен күрсәтик дип, бер төнне [бик кыска бер вакытта Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм колын Харам мәчетеннән [алып] Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әкъса мәчетенә күчерүче кимчелекләрдән пакь. Һичшиксез, Ул – [һәрнәрсәне] Ишетүче, Күрүче», – дип әйтә.*

*«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:1*

«Әл-Исра» сүрәсенең беренче аяте Аллаһының шушы сүзләре белән башланып китә. Аллаһы шушы вакыйга белән Пәйгамбәребезне юатырга, аңа көч бирергә теләде. Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәрлегенең унынчы елында аның яраткан бабасы Әбү Талиб вафат була. Әбү Талиб Пәйгамбәребез белән Кораеш кабиләсе арасында бер киртә булып торды. Үзе исламны кабул итмәсә дә, Аллаһының рәхмәте белән, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмне Кораеш кабиләсе кешеләренең явызлыгыннан саклады, шул сәбәпле, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә үзенең вазифасын башкаруда ярдәм итте. Озак та үтми, өч айдан бабасы артыннан аның иң яраткан кешесе – хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә дә вафат була. Хәдичә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһының зур бер рәхмәте һәм бүләге булды. Ул иң авыр чакларда Пәйгамбәребез белән бергә иде, аңа рухи яктан көч биреп торды, аны сабырлыкка чакырды, күңел төшенкелегенә бирелмәскә өндәде.

Кайгы артыннан кайгы килү сәбәпле, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең йөрәге сыкрады һәм авыртудан тетрәде.

## ИСРА (КИЧКЕ СӘФӘР)

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмне Аллаһы шушы авырлыклар белән сынаса да, Ул аны Үз ярдәменнән калдырмады. Аллаһы Пәйгамбәребезгә күңелен юата, өмет һәм көч бирә торган бер могҗиза күрсәтте: аны бер төн эчендә Мәккәдән Кодес (Иерусалим) шәһәренә һәм аннан җиденче кат күккә – Үз хозурына күтәрде. Бу вакыйга пәйгамбәрлекнең унынчы елында – 27 нче раҗәб ае кичендә булды һәм, Коръәннән кала, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең иң зур могҗизасы иде. Бу хәл болай булды: Пәйгамбәребез төнлә, апасы Өмме Һәнинең йортында диварга сөялеп утырганда (икенче риваять буенча Кәгъбәгә сөялеп утырганда) аның янына ике фәрештә килә. Алар Пәйгамбәребезнең күкрәген ярып, аннан йөрәген алып, Зәмзәм суы белән юалар һәм пакьләп кире урынына куялар. Шуннан соң Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына Борак исемле хайванны җитәкләп, Җәбраил галәйһиссәлам килә. Бу хакта ул үзе сөйли: «Төнлә белән минем яныма Җәбраил фәрештә килде. Ул Борак белән иде. Бу – ишәккә охшаган, ләкин аннан бераз зуррак булган ак төстәге хайван иде. Аңа утырып, мин Бәйтел Мәкъдискә (Иерусалим шәһәре) китерелдем. Әкъса мәчете ишеге төбендә Буракны бәйләп куеп, эчкә уздым һәм барлык пәйгамбәрләр белән, аларга имам торып, намаз укыдым. Намаз укып чыкканда, минем яныма Җәбраил галәйһиссәлам ике савыт тотып килде: берсендә хәмер, икенчесендә сөт иде. Мин сөтне сайладым һәм Җәбраил галәйһиссәлам: «Син пакьлекне сайладың», – диде.

## МИГЪРАҖ (КҮККӘ КҮТӘРЕЛҮ)

Шуннан соң алар күкләргә күтәреләләр. Һәрбер күккә күтәрелгән саен, ул пәйгамбәрләр белән очраша, аларга сәлам бирә һәм андагы серләрне күрә. Ибраһим галәйһиссәлам белән очрашканнан соң, ул Сидратүл-Мөнтәһә исемле агач янына туктала.

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Аллаһының Расүле Сидратүл-Мөнтәһә дигән агач янында тукталгач, аңа өч нәрсә бирелде: биш вакыт намаз, «Әл-Бәкара» сүрәсенең ахыргы аятьләре һәм аның өммәтеннән Аллаһыга тиңдәшлек кылмаучының гөнаһлары ярлыкануы» (Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Шулай ук Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә Мигъраҗ вакытында җәннәт һәм аның әһелләре күрсәтелде. Ул җәннәттә булып, аңа биреләсе Кәүсәр елгасы китерелде, җәһәннәм һәм аның әһелләре, төрле гөнаһ кылучылар һәм аларның нинди җаза алулары күрсәтелде. Болардан соң Расүлебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кире кайтарылды.

## ДӘРЕСЛӘР

Бу вакыйгадан без бик күп гыйбрәтләр алабыз. Шулардан: Пәйгамбәребезнең башка расүлләрдән булган өстенлеге. Әлбәттә, Аллаһы һәр расүлгә бер өстенлек бирде. Аллаһы Тәгалә Расүлебезне пәйгамбәрләрнең соңгысы итте, аны бөтен дөнья халкына Расүл кылды һәм аңа моңарчы бер кешегә дә күрсәтмәгән күкләрнең серләрен ачты, аның белән турыдын-туры сөйләште. Беркем дә әле мондый өстенлекләргә ия булмады.

Кодестагы Әл-Әкъса мәчете мөселманнар өчен Әл-Харам мәчете кебек изге урындыр. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу мәчеттә укылган намаз, башка мәчетләрдә укылган намазлардан, биш йөз тапкырга өстенрәк», – диде.

**Марат хәзрәт Сәйфетдинов,**
Балтач үзәк мәчетенең
икенче имамы

**Безне иң камил рәвештә яраткан, күркәм тәрбия биргән һәм, пәйгамбәребез Мөхәммәд саллəллаһу галәйһи вә сәлләмне җибәреп, безгә карата Үзенең рәхмәтен белдергән Аллаһы Тәгаләгә барча мактаулар булсын! Иң югары әхлак үрнәге булып һәм кылырга мөмкин булган иң күркәм һәм бәя биреп бетергесез гамәл булып дини тормышыбызда әдәпләрне үтәү, галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләнең әмерләренә буйсыну һәм пәйгамбәрләр холкына хас изге гамәлләр кылу тора. Коръәни Кәрим һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд саллəллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте аша Аллаһы Тәгалә безгә әдәпләрне өйрәткән.**



Фото: yandex.com

## МӨЭМИННЕҢ АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ КАРШЫНДАГЫ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Башны һәрвакыт алга таба иелгән килеш тотарга
- ✔ Фикерләреңне бергә тупларга
- ✔ Дәшмәскә яки аз сөйләшергә
- ✔ Кирәк булмаган хәрәкәтләр ясамаска, тыныч булырга
- ✔ Әмерләрне үтәргә тырышырга
- ✔ Тыелганнардан читләшергә
- ✔ Артык каршы килмәскә
- ✔ Күркәм әхлакка ия булырга
- ✔ Һәрвакыт зикердә булырга, Аллаһы Тәгаләне истән чыгармаска
- ✔ Йөрәкне начар уйлардан пакьләргә
- ✔ Әгъзаларны сакларга
- ✔ Җан тынычлыгын сакларга
- ✔ Аллаһы Тәгаләне зурларга
- ✔ Үпкә сакламаска
- ✔ Яраткан нәрсәне сер итеп сакларга
- ✔ Һәрчак ихлас булырга
- ✔ Һәрвакыт хакыйкать яклы булырга
- ✔ Кешеләргә таянмаска
- ✔ Гамәлләр кылуда ихлас булырга
- ✔ Ширек кылмаска һәм икейөзлелектән сакланырга
- ✔ Гадел (дөрес) булырга
- ✔ Аллаһыга якынайта торган гамәлләр кылырга
- ✔ Артык кул хәрәкәтләре ясамаска
- ✔ Тыелган гамәлләр кылынганны күргәндә ачуланырга
- ✔ Һәрвакыт тәкъва булып калырга
- ✔ Оялчан булырга
- ✔ Курку белән өмет арасындагы халәттә булырга, ягъни Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткәннәргә ышанырга
- ✔ Аллаһы Тәгаләнең аның өчен иң яхшысын насыйп итәчәген тәгаен белеп, һәрнәрсәдә Аңа тәвәккәл кылырга
- ✔ Бер намазны мәчеттә кылганнан соң, киләсе намазның вакыты керүен көтеп алырга
- ✔ Фарыз намазны калдырудан куркып сискәнергә
- ✔ «Бәлки мин берәр гөнаһта даимчелек кылам» дип куркып, һәрчак тәүбәдә булырга
- ✔ Аллаһы Тәгаләне искә алганда сискәнеп куярга
- ✔ Нәсыйхәт һәм киңәшләргә колак салырга
- ✔ Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләре аркылы хәбәр иткән һәм биш сизү-тоемлау әгъзалары ярдәмендә тоеп булмый торган нәрсәләрнең хаклыгына иман китерергә
- ✔ Мохтаҗ вакытта Аллаһыга тәвәккәл кылырга
- ✔ Саран булмаска һәм мөмкинлек булганда садака бирергә

## КОРЪӘН ӨЙРӘТҮЧЕНЕҢ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Тәкъва һәм җитди кыяфәт белән утырырга
- ✔ Шәкертләрнең укуын тыңларга
- ✔ Аңлар өчен, сөйләшмәскә
- ✔ Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын өмет итәргә
- ✔ Охшаш (ясалышы ягыннан якын) хәрефләрнең әйтелешенә игътибар итәргә
- ✔ Коръән укыган вакытта вакыф (туктау) урыннарын шәкертләргә төгәлрәк әйтеп барырга
- ✔ Укуны туктатканда, укуны дәвам итүнең тәртипләрен аңлатырга
- ✔ Саннарны өйрәтергә
- ✔ Тәҗвид һәм авазларның дөрес әйтелешен өйрәтергә
- ✔ Хәтем чыгу (Коръәнне тулысынча уку) фазыйләтләрен һәм хәтем чыкканнан соң үтәлергә тиешле гамәлләрнең тәртибен аңлатырга
- ✔ Күптән түгел генә Коръән укый башлаган шәкертләрне аңлап, аларга карата йомшак мөгамәләдә булырга
- ✔ Шәкерт дәрескә килмәгәндә, дәрес калдыруының һәрвакыт сәбәбен сорарга
- ✔ Әлеге шәкерт дәрескә килгәч, аны укырга өндәргә
- ✔ Аз сөйләшергә
- ✔ Шәкертләргә намазда укыла торган аять-сүрәләрне яки алар имам булгач укырга кирәк булачак сүрәләрне ятлатырга

## КОРЪӘННЕ ӨЙРӘНҮЧЕНЕҢ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Остаз каршында тыйнак кына утырырга
- ✔ Остаз сөйләгәннәрне аңлар өчен игътибарлы булырга
- ✔ Башны бераз аска иярgә
- ✔ Коръәнне укый башлар алдыннан остаздан рөхсәт сорарга
- ✔ Шуннан соң «Әгуузү-бисмилләһ»не әйтергә
- ✔ Укуны тәмамлаганнан соң, дога кылырга

## ВӘГАЗЬ СӨЙЛӘҮЧЕНЕҢ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Үзен югары тотмаска
- ✔ Аллаһы Тәгаләдән оялырга
- ✔ Мохтаҗ вакытта Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәргә
- ✔ Тыңлаучыларның сөйләнгәннәрдән гыйбрәт алуларын теләргә
- ✔ Үзеңнең кимчелекләрең хакында белеп, тыйнак булырга (үзеңне лаеклы түгел дип санау)
- ✔ Тыңлаучыларга карата яхшы мөгамәләдә булырга
- ✔ Тыңлаучыларыңның җитәрлек дәрәҗәдә тәкъва булуларына ышанырга
- ✔ Гайбәт тозагына эләкмәү өчен, тыңлаучылардан бүләкләр көтмәскә
- ✔ Тәрбия биргәндә түбәнчелек күрсәтергә, ачык йөзле булырга һәм ягымлы итеп сөйләргә
- ✔ Яңа килгән тыңлаучыларга карата игътибарлы булырга
- ✔ Үзе сөйләгәннәрне катгый рәвештә үтәргә ниятләргә, чөнки кешеләр аның сүзләреннән генә түгел, гамәлләреннән дә гыйбрәт ала

## ВӘГАЗЬ ТЫҢЛАУЧЫНЫҢ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Игътибарлы булырга
- ✔ Башны азрак аска иярgә
- ✔ Чиста күңелле булырга
- ✔ Яхшы фикердә булырга
- ✔ Сөйләгәннәрнең хак булуына ышанырга
- ✔ Сөйләшмәскә
- ✔ Кирәкмәгән хәрәкәтләр ясамаска (уңга-сулга боргаланмаска)
- ✔ Вәгазьне игътибар белән тыңларга

**Имам Әбү Хәмид Әл-Газалинең «Әдәпләр»** китабыннан

*(Дәвамы бар)*

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 02 (319) февраль, 2022 | җөмәдәл-ахыр – раҗәб, 1443

# Г. Барудиның тууына 165 ел тулу уңаеннан фәнни җыен узды


Фото: dumrt.ru

**15 нче февральдә Казанда мәгърифәтче, педагог, татар дин галиме Галимҗан Барудиның 165 еллык юбилее алдыннан республикакүләм фәнни-гамәли конференция узды. Ул «Татар дин галимнәренең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мирасын саклауга һәм өйрәнүгә керткән өлеше» исеме астында оештырылды.**

Конференцияне Апанай мәчете мәдрәсәсендә үткәрү юкка түгел: Г. Баруди биредә 1862 елдан алып 1875 елларга кадәр белем алган һәм үзе дә укыткан. Шуннан соң Урта Азиягә китеп белемнәрен арттырган. Аннары Казанга кайткач, әтисе белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә нигез салган һәм аны җитәкләгән, бик күп шәкертләрне тәрбияләгән, бик күп дәреслекләр язган. Шунысын ассызыклап әйтергә кирәк, Галимҗан хәзрәт Баруди – татарларны гына түгел, башка мөселман халыкларын да тәрбияләгән, аның шәкертләре арасында гарәпләр дә булган.

Г. Барудиның зур, дәрәҗәле, киң карашлы, гыйлемле шәхес булуы турында үзенең чыгышында беренчеләрдән булып Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин билгеләп үтте. «Галимҗан Барудиның шәкертләре чит илләрдә дә бар. Мәсәлән, Габдрәуф Җума – зур галим, Әл-Әзһар докторы. Ул Галимҗан хәзрәтебезнең шәкертенең шәкерте булып санала. Ибраһим Мурейхи – Бәхрәйнның шәригать казые булып эшли, ул шулай ук Әл-Әзһар докторы, Нәкышбәндия тарикате шәехе, аның чылбыры Галимҗан хәзрәтебездән килә. Ибраһим Мурейхи «Казан галимнәренең иҗазәтләре» дигән өч томлык китап әзерләде һәм ул быел дөнья күрәчәк. Без ул китаптан чылбырларны тикшереп, барлап, киләчәктә күп галимнәребезне өйрәнә алачакбыз. Бу китапны укып, без бик күп кызыклы мәгълүматларга тап булабыз. Мәсәлән, Галимҗан хәзрәт Баруди Җәләләйн тәфсирен Мәрҗани хәзрәтебездән укыган һәм иҗазәт алган. Габделҗәлил Дур-Димәшки «Кутбе ситтә»не Галимҗан хәзрәтебездән укый һәм иҗазәткә ия була. Безнең галимнәребез турында еш сөйләргә, аңлатырга кирәк. Алар безнең өчен үрнәк», – дип билгеләп үтте үзенең чыгышында Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр комитеты җитәкчесе Альберт Борһанов конференцияне оештыручыларга рәхмәт сүзләрен әйтте һәм шәхсән үзе тарафыннан Галимҗан Барудиның тормыш юлын өйрәнүне 1995 елдан алып баруын, Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан конференцияләр үткәрү буенча тәкъдимнәрен җиткерде.

Рәсми сәламләү сүзләрен шулай ук «Иске шәһәр» территориясе префекты җитәкчесе урынбасары Раннур Шәрипов, Казан Башкарма комитетының Телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге җитәкчесе Илнур Шакиров, Рәсәй Федерациясе Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов җиткерде.

Апанай мәчетенең имам-хатыйбы, «Иман» мәдәният-мәгърифәт үзәге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабиров Галимҗан Барудиның «Иман» нәшриятында яңа гына дөнья күргән «Бер-бер артлы килүче кырыгар хәдисләрдән торган беренче китап» басмасын тәкъдим итте. Китап гарәп теленнән хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемә ителде. Кайбер хәдисләргә аңлатмалар да бирелде.

Тарих фәннәре докторы Фәйзелхак Ислаев: «XX йөз башында ренессанс чорын татар имамнары оештырган. Шулар арасында иң якты йолдыз – Баруди, чөнки 1918 елның маенда мөселманнар Мәскәүдә съезд үткәргән, беренче тапкыр мөфтине мөселманнар үзләре сайлап куя. Алар Галимҗан хәзрәт Барудины сайлый, чөнки мөселманнар иң абруйлы дин әһеле дип аны таныганнар. Рәсәйдә ислам дине буенча иң алга киткән халык татарлар булган. Аның нигезе Болгар дәвереннән килә. Дин безгә Мөхәммәд пәйгамбәр исән вакытта ук килгән, 922 елда Ислам дине дәүләт дине дәрәҗәсенә күтәрелгән», – дип билгеләп үтте.

Г. Барудиның тормыш юлы һәм дин-мәгърифәт юлында куйган хезмәтләре хакында Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсә мөгаллиме Равил хәзрәт Бикбаев сөйләде. «Галимҗан хәзрәт киң карашлы, җәмгыятьтән аерылмаган, берни агымнар яки төркемнәр ягына авышмыйча, инсафлы, гадел галимнәрнең берсе була. Безнең киләчәгебез өчен әлеге шәхесне өйрәнү, аның кебек булырга омтылу, төрле мәсьәләләргә карап хөкем итү бик мөһим. Ул беркайчан да халыктан аерылмаган, хәтта «Әд-Дин вәл-Әдәп» журналында Коръән тәфсир кылганда яки хәдисләргә аңлатма биргәндә халыкта нинди мәсьәләләр мөһим булса, шуларга игътибар иткән. Мәсәлән, XX йөз башында ачлык тарала башлагач, күбрәк иганәчелек, садакалар бирүнең әһәмияте турында бик күп язмалар бастырган. Аны халык һәм дин әһелләре бик яраткан».

**dumrt.ru** сайтыннан

# Нух галәйһиссәлам көймәсе

**Адәм галәйһиссәламнең вафатыннан соң күп вакыт үтте, кешеләр үзләренең Адәм балалары икәнлекләрен онытып, җир йөзендә тәртипсезлекләр кыла башлады.**

Көчле һәм бай кешеләр зәгыйфь һәм ярлыларны рәнҗетте, дөньяда гаделсезлек таралды, Адәм балаларының йөрәкләре таш кебек катты, алар изгелек кылу, мәрхәмәт, шәфкать төшенчәләрен онытты. Моннан тыш, үз куллары белән сыннар ясап, шуңа табына башладылар, Аллаһыга итагать итүдән баш тарттылар.

Нәкъ шул вакытта Аллаһы Тәгалә Нух исемле кешене пәйгамбәр итеп җибәрде. Нух галәйһиссәлам һәрвакытта да изгелекле һәм гадел кеше иде, ул гел дөресен генә сөйләде һәм көченнән килгән кадәр ярдәмгә мохтаҗ булучыларга булышып яшәде.

Нух галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән пәйгамбәрлек вазифасын кабул иткәннән соң, кешеләрне бер илаһлыкка чакыра башлады, аларга дөрес яшәмәгән очракта беркайчан да җирдә тынычлык, иминлек булмаячагын аңлатырга тырышты, әмма аны тыңларга да теләмәделәр. Аннан көлеп: «Син бит безнең кебек үк кеше. Нигә без сине тыңлап торырга тиеш?!» – дип әйтә торган иделәр. Бик аз кеше генә аның пәйгамбәрлеген танып, Нух галәйһиссәламгә иярде, күбесе Аллаһының пәйгамбәрен мыскыл итте һәм хәтта аңа үтерү белән яный иде. Әмма бу хәлләргә дә карамастан, Нух галәйһиссәлам үз сүзендә нык торды, кешеләрне хакыйкатькә – Аллаһы диненә кайтуга чакыруын дәвам итте.

# Аллаһыдан ярдәм сорау

Ләкин пәйгамбәр галәйһиссәлам күпме генә тырышса да, шәһәр халкының һәм байларның йөрәкләре йомшармады. Шуннан соң ул Аллаһыдан ярдәм сорап мөрәҗәгать итте. Моны белгән иман китермәгән кешеләр: «Карыйк әле: синең Раббың безгә җәзасын бирсен», – дип, Нух галәйһиссәламне мыскыл итте. Алар тарафыннан басым, усаллык шул дәрәҗәгә җитте ки, пәйгамбәр галәйһиссәлам Аллаһыга болай дип дога кылды: «Йә Аллаһы! Мине һәм мөэминнәрне коткар».


Фото: shutterstock.com


### АЛЛАҺЫНЫҢ КӨЙМӘ ТӨЗЕРГӘ ӘМЕР ИТҮЕ

Болардан соң Аллаһы Тәгалә Нух галәйһиссамгә көймә төзергә әмер бирде. Моңа кадәр мондый зур эшне берәүнең дә башкарганы булмаганга, пәйгамбәргә көймә төзү тәртибен Үзе өйрәтте. Нух галәйһиссәлам мөэминнәр белән бергә урманнан агач ташып, көймә төзү эшенә керәште. Җиткереп чыкканнан соң, Раббыбыз аңа бу көймәгә мөэминнәрне һәм һәрбер төр хайваннан бер парны кертергә кушты.

Иман китермәгән кешеләр бәла киләсен сизмәде. Икенче көнне күк йөзен кап-кара болытлар каплап алды, каты итеп күк күкрәде, коеп яңгыр ява һәм су күтәрелә башлады. Аллаһының пәйгамбәренә ышанмаучы кешеләр тауларга йөгерде, әмма бу аларга ярдәм итмәде. Бертуктаусыз яуган яңгырдан соң бер урында да коры җир калмады һәм су бөтен нәрсәне үз эченә йотты.

*Дәвамы киләсе санда, нәни дустым!*

Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде



Җәлил хәзрәт Фазлыевның **«Тигез гомер итегез»** китабы

**Җаваплы адымга әзерләнгән – гаилә корырга ниятләгән һәр парга нәсыйхәт бирү мөһим. Әлеге китапта матур, тату мөселман гаиләсен төзү, аны саклауга багышланган вәгазьләр тупланган. Шулай ук катнаш никах, балага мәгънәле, шәригатебезгә муафыйк исем бирү мәсьәләләре яктыртыла.**

Гаилә учагында бәхет, бәрәкәт яшәсен өчен, иман кирәк. Һәр гаилә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырлык итеп яшәсен, дигән изге теләк белән, автор китапта Коръәннең иң еш укыла торган сүрә-аятьләрен китерә һәм намаз уку тәртибен өйрәтә.

Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләреннән сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.

- КИБЕТ: Казан шәһ., Париж коммунасы ур., 6нчы йорт. Тел.: +7 960 072-74-63;
- СКЛАД: Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт. Тел.: +7 (966) 250-00-09;
- Интернет-кибет: huzurshop.ru

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 02 (319) февраль, 2022 | җөмәдәл-ахыр – раҗәб, 1443

# VIII – XIII ГАСЫРЛАРДА УРТА ИДЕЛДӘ ИСЛАМ



Фото: shutterstock.com

**VII гасыр уртасына Көнбатыш Аурупада төрки каһанлыклар көчсезләнә башлый һәм Кара диңгез буе далаларында Бөек Болгар дәүләте барлыкка килә.**

Кубань далаларында һәм Кара диңгез буенда яшәгән болгар кабиләләре якынча 603 елда үзләренең этносәяси берләшмәләрен оештыралар. Күпмедер вакыт берләшмә Авар каһанлыгына буйсынып тора, 635 елда болгарлар башлыгы Орган һәм аның Византия императоры сараенда үскән туганы Кубрат (якынча 619 елда шунда чукындырылган булуы мөмкин) Авар каһанлыгын җимереп, Кара диңгезнең көнчыгыш өлешендәге далаларында тарихка Бөек Болгар исеме белән кереп калган кабиләләр берләшмәсен төзи. Гадәттә, болгарларның бабаларын Идел-Урал төбәгенә кергән чорларда мәҗүси булган, дип саныйлар. Болгарларның дини ышанулары төрки мәҗүсилеккә нигезләнгән була. Мәҗүсилек кояшка, айга, яшен, биек агачларга табынудан гыйбарәт була. Әмма бу чорда төбәктә дини вәзгыять шактый катлаулы була.

Бөек Болгар дәүләте таркалгач, Кубратның биш улы үз кабиләләре белән Түбән Дунай, Паннония, Урта Идел буе, Дон буе, Төньяк Кавказ җирләренә тарала.

Болгар кабиләләре VII гасыр ахырында, Идел буена күчкәннән соң, төрки-угыр халкы белән кушыла. Дәүләт формалашу чорында иң көчлеләрдән Алмыш хан җитәкчелек иткән кабиләләр санала.

Урта Иделдә болгар дәүләте формалашкан чорда дини вәзгыять авыр, төрки-болгар кабиләләренең рухи мәдәнияте катнаш хәлдә була.

VII гасыр ахырында, Көнчыгыш белән даими сәүдә мөнәсәбәтләре урнаша башлагач, һәм Идел-Балтыйк сәүдә юлы ачылгач, мөселман илләре белән элемтәләр ныгый. Төбәктә Исламны тану һәм дингә өндәүчеләр барлыкка килү чоры да шул вакытка туры килә.

Болгарлар арасында Исламның таралуы Шилки һәм улы Алмыш кул астындагы төрле кабиләләрнең берләшүенә бәйле була. Моңа Хазар каһанлыгыннан бәйсез булу теләге этәргеч ясый. Алмыш, Идел-Урал төбәгендәге башка төрки-угыр кабиләләренең юлбашчылары кебек, хазар каганына буйсынып, аңа эшкәртелгән тиреләр белән ясак түләп тора, ә улы Хазар дәүләтенең башкаласы Итилдә тоткынлыкта була.

Ни өчен Идел буенда нәкъ менә Ислам дине тарала? Бер яктан, насара дине, Византия Хазар дәүләте белән бердәмлектә булганлыктан, Идел буе төбәгенә бернинди дә тәэсир ясамый. Икенче яктан, Идел буе дәүләтенең Урта Азиядәге Хәрәзем, Саманидлар мәмләкәте белән икътисадый-сәүдә мөнәсәбәтләренең үсеше тәэсир итми калмый. Урта Иделгә ачылган туры сәүдә юлы Хазар дәүләтен читләтеп уза торган була.

Шулай итеп, Ислам Идел буена Урта Азиядән һәм Бохарадан килгән булып чыга. Алмыш ханның Ислам кабул итү көне төгәл билгеле булмаса да, X гасырның беренче унъеллыгы дип санарга мөмкин, чөнки язмалары 903-913 елларга караган күренекле гарәп сәяхәтчесе Ибне Рөстә «Болгар ханы Алмыш һәм болгарларның күп өлеше Ислам динен тота. Шулай ук авылларында мәчетләре һәм башлангыч белем бирү уку йортлары бар», – дип яза. Бүгенге көндә тарихчылар тарафыннан тикшерелеп, 922 ел Болгар дәүләтенең рәсми рәвештә Ислам динен кабул итү елы дип санала.

Шулай ук, Ислам диненең Болгар дәүләтенә үтеп керүенең тагын бер риваяте бар. Ул Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өч сәхабәсен җибәрү. Риваять буенча шул сәхабәләр Идел буенда урнашкан халыкларны Изге китап – Коръән белән таныштыралар. Сөекле Пәйгамбәребез исән вакытта ук үзенең өч сәхабәсен, кулларына өч төрле әйбер: чалма, таяк, каләм карасы савыты тоттырып, Идел буе җирлегенә җибәрә. Нәкъ менә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм биргән таякка таянып килгән сәхабәләр беренче вәгазьләр сөйлиләр. Барлыгы Идел буе җирләрендә бу өч сәхабә 12 ел дәвамында Исламга чакыру эшен алып баралар. Соңыннан, ике сәхабә кире Мәдинә шәһәренә кайтып китә, өченчесе Болгар дәүләтендә тормыш итәргә калып, шунда җирләнә.

Турыдан-туры булмаса да, әлеге риваятьне дәлилли торган язмалар XII гасыр гарәп сәяхәтчесе Габдулла Әл-Гарнатидә чагылыш тапкан. Ул язмалар буенча Пәйгамбәребез һиҗри буенча 9 нчы елда өч сәхабәсен Болгар җирлегенә җибәрә дигән. Татар халкының мәшһүр галиме Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре дә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында төрки телле шәхес булган һәм ул Пәйгамбәребезнең юлламасын төрки телгә тәрҗемә итеп, ул хат Идел буе җирләрендә яшәүче халыкларны Ислам дине белән таныштыру өчен фәрман буларак, бу төбәккә юлланган дип фаразлый.

Шуны да исәпкә алырга кирәк, Багдад хәлифәтенең илчелеге Болгар дәүләтенә килгән вакытта, биредә мәчет һәм мәдрәсәләр була. Бу хәлне Багдад илчелегенең сәркатибе Әхмәд бине Фадлан үзенең язмаларында мәгълүмат итеп бирә. Әлеге мәгълүмат, Идел буе, ягъни Болгар дәүләте җирләренә, Ислам дине бу җирлектә рәсми рәвештә кабул итү елы алдыннан ук таралуына бер дәлил булып тора.

Ислам динен рәсми кабул иткәч, болгарлар арасында мөселман мәдәнияты йогынтысы көчәя башлый, болгар шәһәрләрендә һәм авылларында мәчетләр төзелә, мәдрәсәләр ачыла.

IX гасыр ахырыннан башлап Ислам җәмгыятьнең рухи мәдәниятына ныграк үтеп керә һәм мәҗүсилек ышануларын хорафатка чыгарып калдыра. Дәүләтнең чәчәк атуы, шәһәрләр үсеше, илнең һәр тарафында мөселманча рухи һәм матди мәдәниятнең җәелүе болгарларның бердәм этносәяси бердәмлеген формалашуга этәргеч була.

**«Ислам дине нигезләре»**
китабыннан




Фото Ерак Шәрыкта чыккан «Милли Байрак» гәҗитеннән алынды.

ХАРБИН МӘЧЕТЕНДӘГЕ БЕРЕНЧЕ ҖОМГА НАМАЗЫ. 1937 ЕЛНЫҢ 8 НЧЕ ОКТЯБРЕ

# Харбин шәһәрендә Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы билгеләп үтелгән

*Болгарларның Ислам динен кабул итүләре хөрмәтенә Кытайда ачылган мәчет*

**Быел Рәсәй мөселманнары зур вакыйга билгеләп үтә: моннан 1100 ел элек Идел болгарлары – бүгенге заман татарларының ата-бабалары Ислам динен үз дәүләтләренең рәсми дине итеп таныган. Шушы вакыйгадан файдаланып, Кытайда болгарларның Ислам динен кабул итүе хөрмәтенә төзелгән борынгы мәчет хакында сөйләп үтик.**

1922 елда болгар бабаларыбыз Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгын билгеләп үткәндә, кызганычка, атеистик большевистлык режимы сәбәпле, Рәсәйдә бу зур датаны тиешенчә уздыру мөмкин түгел иде. Шуңа күрә 1922 елда Ерак Көнчыгыштагы татар иммиграциясенең үзәге булган Харбин шәһәре бу чараны уздыруны үз өстенә алган.




Фото: google.com

МӘЧЕТ БИНАСЫНДАГЫ ЯЗУ ТАКТАСЫ

1922 елда татарлар монда онытылмаслык зур бәйрәм ясаган, шулай ук махсус юбилей альбомы чыгарганнар. Катнашучылар тарафыннан истәлекле дата хөрмәтенә Харбинда бөтен Ерак Көнчыгышның асылташы булачак мәчет төзү карары кабул ителгән.

Ул вакытта татарларның Харбинда мәчетләре булса да, ул зур булмаган. Яңа мәчет шәһәрнең бизәге булыр һәм шулай ук «Болгарларның Ислам динен кабул итүенә 1000 ел» исемен алыр дип көтелгән. Әмма, әлбәттә, мондый зур төзү эшләре шактый чыгымнар таләп иткән. Харбинның татар җәмәгатьчелегендә андый акчалар булмаган. Моннан тыш, Рәсәйдәге революция, ә аның артынннан башланган Гражданнар сугышы сәбәпле, күп гаиләләрнең матди хәле какшаган.

Әмма моңа карамастан, халык мәчет төзү һәм бу истәлекле вакыйганы тарихка кертеп калдыру карарын кабул иткән. 1923 елда төзелеш эшләре башланган. Матди ярдәмне Харбин һәм Маньчжуриянең калган шәһәрләреннән булган татарлар гына түгел, ә Япония һәм Корея татар диаспорасы вәкилләре дә күрсәткән.

1923 елда Артиллерия урамында (хәзерге Тунцзянцзе урамы), иске мәчет урынында (беренче агач мәчет татарлар тарафыннан 1901-1906 елларда төзелгән була) таш мәчет төзелә башлый. 1924 елда мәчетнең төп эшләре тәмамлана һәм 1924 елның 27 нче июлендә манарага тантаналы рәвештә ярымай урнаштырыла. Әмма 1926 елда Харбин шәһәренең төзүне үз кул астына алган имамы – Гыйниятулла Салихмәт (Салихмәтов) вафат була. Күп еллар дәвамында ул Харбинның гына түгел, ә бөтен Ерак Көнчыгыш татар җәмәгатьчелегенең рухи лидеры булып тора.

Аның үлеменнән соң төзелеш эшләре акрыная, мәчет җыелган садака акчалары белән генә төзелә башлый. Төзелешкә шулай ук Кытайның 1929 елда СССР белән, ә 1931 елда Япония белән булган хәрби конфликтлары комачау итә. Моның өстенә 1932 елда Харбинда зур су басу була. Татарларның барысы да диярлек Сунгари елгасы янында яшәгәнлектән, бөтен нәрсә, шул исәптән төзелә торган мәчет тә зыян күрә.

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Дамир Гайнетдинов** язмасы,
islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә

# БӘРАӘТ КИЧӘСЕ

**Бәраәт сүзе гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә, «бурычтан вә җәзадан пакьләнү», дигәнне аңлата. Шәригать буенча мәгънәсе – «гөнаһлардан котылу», «бәхет», «иминлек», «уңыш», «изгелекләр иңә торган кичә».**

Шуңа бу кичәдә мөселманнар Аллаһыдан үзләренең, мәрхүмнәренең гөнаһларын ярлыкавын сорап дога кылалар. Бәраәт кичендә Коръәни Кәрим, бөтен мәгълүматлар саклана торган «Ләүхүл-Мәхфүз» китабы беренче кат күккә иңгән дип санала. Бу изге кичәне Кадер кичәсе белән бутаучылар очрый. Ләкин алар төрле дәрәҗәгә ия булган, аерым мәгънәле кичәләр.

Пәйгамбәребез: «Шәгъбан аеның 15нче көне керсә (14 шәгъбаннан 15 шәгъбанга каршы төн Бәраәт кичәсе була), аны гыйбадәт белән үткәрегез», – дигән. Шулай ук көндез ураза тоту хәерле, чөнки Аллаһы Тәгалә ул кичне кояш чыкканчыга кадәр дөнья галәменә рәхмәтен җибәрер: «Тәүбә һәм истигъфар итүче булса, аны гафу итәм. Ризык сораучы булса, аңа ризык бирәм. Авыруга дучар булса, аңа саулык-сәламәтлек бирәм. Бармы андый кешеләр?» – дип сорар.

Сүз уңаеннан, быел Бәраәт кичәсе 17 нче март көнне ахшам намазыннан соң керә.

Бәраәт кичендә өстәмә тәһәҗҗөд намазын укырга кирәк. Гөнаһларны искә төшереп, күбрәк тәүбә кылыйк, «Йәсин», «Мүльк» («Тәбарәк») сүрәләрен укыйк, зикерләр, Пәйгамбәребезгә салаватлар әйтик, бу көнне күбрәк изге гамәлләр кылырга тырышыйк.

**Дини календарь 2022**

# Аллаһы дусларының ихласлыгы



Фото: shutterstock.com

**Мәлик бине Динар рахимәһуллаһиның әтисе күпмедер вакыт бер кешенең җиләк-җимеш бакчасында эшләгән. Көннәрдән бер көнне ул хуҗасына: «Мин эштән китәм, өемә кайтып, үз эшем белән шөгыльләнәсем килә», – дип әйткән.**

Хуҗа кеше: «Ярый, әмма мин карт, бакчага чыгарлык хәлем юк, миңа алмагачның һәр төреннән берәр алма алып кер әле», – дигән. Мәлик бине Динар рахимәһуллаһиның әтисе өч алма алып кергән. Хуҗа бер алманы кабып караган – ул әче булган, икенчесен кабып караган, ул да әче булган. Өченчесен кабып карагач, анысының да әче икәнен аңлаган. Ул: «Син нәрсә махсус шулай эшлисеңме әллә? Син нигә баллы алмалар алып кермәдең?» – дигән.

Мәлик бине Динар рахимәһуллаһиның әтисе: «Мин аларның кайсы баллы булуын белмим», – дип җавап кайтарган. Хуҗа: «Син никадәр вакыт биредә эшләдең, әллә алма ашап карамадыңмы?» – дип сораган. Ул болай дип җавап биргән: «Син мине эшкә алганда, миңа теләгән вакытта алмаларны ашарга ярый, дип әйтмәдең».

Әлбәттә, мондый кешедән Мәлик бине Динар рахимәһуллаһи кебек бала туган.

# Башкаларны үзеңнән өстен кую

**Әбү Җәһәйм бине Хозәйфә радыяллаһу ганһе болай дип сөйләгән. «Ярмүк» сугышы вакытында мин яралылар арасында абыемның улын эзләдем. Минем бераз суым бар иде һәм мин үземә: «Әгәр аны исән көе тапсам, аңа су биреп, йөзен сөртер идем», – дидем.**

Бу вакытта көтелмәгәндә мин аны үз янымда күрдем. Мин аннан: «Сиңа су бирергәме?» – дип сорадым. Ул, әйе, дигәнне белдереп, башын какты. Бу вакытта тагын берәүдән ыңгырышкан тавыш ишетелде. Абыемның улы миңа башын селкеп, аңа су бирүемне кушты. Бу кеше Хишам бине Гас иде. Мин аннан: «Сиңа су бирергәме?» – дип сорадым. Бу вакытта тагын кемнеңдер ыңгырашуы ишетелде. Хишам миңа, суны аңа илтүемне сорап, башын какты. Мин суны илтә киттем, әмма аның янына килеп җиткәндә бу кеше үлгән иде. Мин Хишам янына кайттым, әмма ул да үле иде инде. Шуннан соң мин абыемның улы янына юнәлдем, әмма ул да вафат булган иде.

### НӘСЫЙХӘТ

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

*«Үзләрендә ихтыяҗ булса да, [ашамыйча-ашатып, киенмичә-киендереп] аларны үзләреннән өстен күрәләр».*

*«Әл-Хәшр / Җыен», 59:9*

**«Рухуль-Бәйан»** китабыннан

# ӨММЕ ХӘБИБӘ РАДЫЯЛЛАҺУ ГАНҺӘ




Фото: wikipedia.org

**ИСЕМЕ:** Өмме Хәбибә Рамлә бинте Әбү Суфиян радыяллаһу ганһә. Туган вакытында аңа Рамлә дип исем кушсалар да, бик еш аңа Өмме Хәбибә дип эндәшкәннәр.

**ТУУЫ:** Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә Мәккәдә, якынча 594 нче елда дөньяга килгән.

### ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮЕ

Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә Ислам динен кабул иткән беренче мөселманнардан. Беренче ире – Гобәйдулла бине Җәхеш, хатыны белән бергә, дәгъватның беренче елларында ук Ислам динен кабул иткән.

Аларның Ислам динен кабул итүләре хакында белгәч, Кораешләрнең нык ачулары чыккан. Бигрәк тә Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең әтисе үз кызының Ислам динен кабул итүе белән килешә алмаган. Аны бу фикереннән кире кайтарыр өчен бик күп тырышлыклар куйган. Ләкин Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә үз карарында нык торган һәм үз фикерен үзгәртер өчен бернинди мөмкинлекләргә дә юл куймаган.

Кызының фикерен үзгәртә алмавына ата кеше бик борчылган. Ул аның бу гамәлен әтисен хөрмәт итмәү буларак кабул иткән. Шуңа да, Әбү Суфиян кызы һәм кияве белән туганлык мөнәсәбәтләрен өзгән. Бу хакта белгән Кораешлеләраларга ачык рәвештә көрәш игълан иткәннәр.

### ХӘБӘШӘГӘ ҺИҖРӘТ

Корәешлеләрнең эзәрлекләүләренә түзәргә мөмкинлек калмагач, Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә һәм аның ире икенче дулкын һиҗрәт кылучылар белән Хәбәшәгә күченеп киткәннәр. Нәҗәши исемле дәүләт башлыгы идарә иткән бу илдә аларны дини яктан беркем дә кысрыкламаган. Озакламый аларның Хәбибә исемле кызлары туган. Шуннан соң инде кызның әнисен «Рамлә» дип түгел, ә «Өмме Хәбибә» дип йөртә башлаганнар. Шушы исем астында ул үзенә танылу алган.

Ислам динен кабул иткәннән соң, әти-әнисе һәм туганнары тарафыннан бик күп авырлыклар күргән Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә Хәбәшәгә күченеп, тыныч тормыш хакында хыялланган, башка мондый төр авырлыклар күрмәмен, дип өметләнгән. Аллаһы Тәгалә аның алдына яңа сынаулар куйган. Шул рәвешле Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең иманы тагын да ныгыган.

Бервакыт ул төшендә ире Гобәйдулла бине Җәхшне бик куркыныч халәттә күргән: иренең йөзе каралган һәм ул тирән кара диңгезгә кереп югалган. Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә бик куркып уянган.

Риваятьләрнең берсендә Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең үз сүзләре китерелә: «Мин ирем Гобәйдулла бине Җәхшне төшемдә күрдем. Ул бик начар һәм куркыныч халәттә иде. Мин бик курыктым һәм болай дип әйттем: «Аллаһы белән ант итәм, ул үзгәргән!» Ә икенче көнгә иртән ул миңа бик ныклап уйлаганын, Ислам диненнән баш тартуын һәм насара диненә күчү карары хакында әйтте. Мин аңа үз төшем хакында да сөйләдем, ләкин ул мине тыңламады».

Гобәйдулла бине Җәхш бу карарыннан соң эчкечелеккә бирелгән, хатынын да үзе сайлаган насара диненә күчәргә өндәгән. Әгәр ул динне кабул итсә, озакламый матди яктан байлыкка ирешәчәкбез, дип кызыктырган. Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәгә ике юлның берсен сайларга кушкан: йә ул Ислам диненнән баш тартып, икенче дингә күчә, яисә ул аны аера.

### НЫКЛЫГЫ ҺӘМ САБЫРЛЫГЫ

Бу хәлләрдән соң Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә кешеләрдән читләшкән, бик нык уйланган, борчылган. Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылып, бу катлаулы мәсьәләләрнең чишелешен Раббысыннан өмет иткән. Ул иреннән талак кылуын сораган һәм үзе кызы белән Хәбәшәдә калырга карар кылган.

Бервакыт ул тагын төш күргән. Төшендә аңа Өмме мөэминин, ягъни мөэминнәрнең анасы дип эндәшкәннәр. Йокысыннан уянгач, бу төшенең хәерле булуына шатланган һәм озакламый пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең аңа өйләнәчәген аңлаган, ләкин бу хакта берәүгә дә әйтмәгән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз сәхабәләренең тормышлары, яшәү рәвешләре хакында гел кызыксынып торган, ярдәм кирәк булганнарына үз көченнән килгәнчә ярдәм иткән. Ул Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең тормышы хакында да ишеткән. Төрле авырлыкларга һәм сынауларга карамастан, матди байлыкларга кызыкмыйча, Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең Ислам диненнән ваз кичмәвенә бик шатланган. Динендә нык торуы бәрабәренә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәне олы дәрәҗә белән бүләкләргә теләгән – аны мөэминнәрнең анасы сыйфатында күрәсе килгән.

### ӨММЕ ХӘБИБӘ РАДЫЯЛЛАҺУ ГАНҺӘНЕҢ ДӘРӘҖӘСЕ

Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәненең дәрәҗәсенә килгәндә, иң элек аның Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә ияреүен атарга кирәк. Аллаһының Расүленнән берәр боерык ишетүгә, ул аңа бик теләп буйсынган һәм ул гамәлне даими үтәргә тырышкан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намазның рәкәгатьләре турында хәдисендә болай дип әйткән: «Кем даими рәвештә көн буена (иртәннән төнгә кадәр) 12 рәкәгать намаз укыса, аңа җәннәттә йорт салыныр». Әлеге хәдисне ишеткәннән соң, Өмме Хәбибә шул рәвешле гыйбадәтен кылган. Бөтен гомерен Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуга һәм Аның әмерләрен үтәүгә багышлаган.

Шулай ук Аллаһы Тәгаләгә якынаю, Аның ризалыгына ирешү өчен ул фарыз гамәлләрне һәм өстәмә нәфел гамәләрне дә башкаруга бик игътибарлы булган. Иренең ризалыгына ирешү өчен дә ул зур көч куйган.

### ВАФАТЫ

Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә 665 нче елда, 70 яшендә вафат булган.

Сәхифәне **Лилия Хәләфетдинова** әзерләде




*(Повестьтән өзек.
Башы алдагы санда)*

...Капка ачылды... Күңеле белән тоеп: «Укучыларым килде!» – диде. Ялгышамы соң? Ул аларның аяк атлап керүләреннән дә таный. Ишектән иң беренче Гөлназ Хәннанова, Алсу Гыйззәтуллина, Зөлфирә Нуриева, Гөлнара Абдуллина керде.

– Яңа ел белән Сезне, Сания Хәлимовна! – дип, өстәлгә күчтәнәчләр куйдылар.

– Онытмыйсыз мине, Аллаһның рәхмәтләре яугырлары! – дип каршы алды.

– Мәктәп елларындагы истәлекләр сезнең белән бәйле бит, апа, ничек онытасың! Класстагы утыз ике баланы поезд белән өч көнгә Уфага, автобусларда Казанга, Бөгелмәгә, Брежнев шәһәрләренә (хәзер Чаллы) алып барганыгызны хәтерлисезме? Сез безгә мәктәп яшендә вакытта ук, дөнья күрсәттегез. Сез биргән белем белән югары уку йортларын тәмамладык, тормышта кирәкле һөнәрләр сайладык, – дип, истәлекләре белән уртаклашканда, мөгаллимәнең күзеннән бәхет яше тамды.

Гөлнара Абдуллина укытучысының кулына «Чакыру билеты» тоттырды.

– Сания Хәлимовна, февраль аенда булачак концертка чакырам, минем җырларымны тыңларсыз, – дигәч, көлемсерәп куйды да:

– Мәдәният йортында сиксән бишь яшьлек кызлар да буламы? – дип сорады.


Үзләре дә илле яшьләренә таба атлаучы ханымнар, мөгаллимәне яратып, үз итеп:

– Сезнең күңел халәтегез үз яшегез белән туры килми: йөзегездә нур уйный, зиһенегез яшь кызларныкы кебек ачык. Концертта көтәбез!.. – диде.

– Килермен, кызларым, килермен, сез миңа картаерга ирек бирмисез, – дип, әйтеп кенә бетерде, шау-гөр килеп, Марат Нургалиев белән Рафаэль Җаббаров килеп керде. Сания апаларына чәчәк бәйләме суздылар, үзен, укучылары белән очрашуга, ресторанга чакырдылар.

...Укучыларының хөрмәтен, җылы карашын тою хисе, өлкән мөгаллимәнең күңел халәтен тагын яшәртте... Күңел гөлләре шигъри юллар булып, «Тормыш китабы»на язылды...

Өлкәнәю – картлык түгел,
Яши белеп яшәү – бәхет!..
Сөй тормышны, сөй гомерне...
Сөй үзеңне!..




## *Җиләкле тау сере*

*(Повестьтән өзек)*

... Әнфисә абыстай башта йортка Коръән укыды. Кияү белән киленгә өлфәт мәхәббәт теләде, матур яшәү серләре белән уртаклашты.

– Авылның йөз күзе бар, аннан берни дә яшерә алмыйсың. Шуның өчен, Айбикә акыллым, гаиләң, ирең турында беркемгә дә, бернәрсә дә сөйләмәскә гадәтлән, шул чакта барысы да тәртип булыр. Ире белән сүзгә килсә дә, акыллы хатын аның эштән кайтуына йөрәк җылысын кушып, тәмле ризык әзерләр һәм шулчакта бар ачуы онытылыр. Үз сүзе дөрес булса да, тормыш көтәм дип яшәгән зирәк ир энә кадәрле сүздән фил ясамас, табын янында хатынына рәхмәт әйтеп кузгалыр. Тормыш чишмәсе янә челтерәвен дәвам итәр, – дип, салмак кына тавыш белән ихлас күңеленнән сөйләвенә, Нурлыбикә әчке канәгатьлек хисе кичереп утырды. Тормыш иткәндә ир белән хатын өчен кирәкле киңәшләр бирүенә куанды.

– Ир-егет өйләнгәнче – чабыш, гаилә коргач, йөк атын хәтерләтә дип тикмәгә генә әйтелми, – ди ул,- – Дөньяның көне күп: хатын-кызга ирен юк-бар сүз белән борчымаска, үз тормышын катлауландырмаска тырышып яшәргә кирәк. Ир белән хатын арасындагы низаг күп очракта тел белән дөрес идарә итә белмәгәннән барлыкка килә. Тел – гаҗәеп көчле корал. Бер сүзең белән пан да була аласың, уйлап әйтелмәгән бер җөмләң аркасында, тормышыңны астын-өскә дә әйләндереп атасың. Әчке ярсуыңны тышка чыгарырга ашыгырга ярамый, тыелып калырга өйрәнсәң әйбәт. Тормыш шулай корылган: гаиләңдә дә, хезмәт урынында да күңелне ярсыта торган кыен сынаулар күп була. Аларның күбесе бездән тормый: язмышка язылган тәкъдир дибез. Шушы авырлыкларны җиңеп чыгарга, йөрәк аша кичерергә Аллаһтан көч сорап яшибез. Сабыр итәр өчен дә рухи көч кирәк бит, җәмәгать.

– Яшәешнең бөек серен гади һәм үтемле итеп аңлаттың да бирдең, Әнфисә абыстай, рәхмәт, – диде Нурлыбикә, күңеле булганын сиздереп. Кодагыеның сүзен Гайникамал да, башкалар да хуплады.

Мәҗлес тәмамлангач, Мәликә абыстай янына күчеп утырды. Ул җайлап кына үзен күптән кызыксындырган сорауларын җиткерде.

– Исеме дә яман чир дип атала бит, шуңа да күңел төрлесен уйлый, – диде Әнфисә. – Минем олы кызым Фәридә Казанда врач булып эшли. Файдалы дип алып кайткан бар ризыгын, ул кушканча пешерәм.

*(Дәвамы бар)*

## ХӨРМӘТЛЕ РАДИОТЫҢЛАУЧЫЛАР!

«Азан» радиосын **azan.fm** сайтында яки **«АЗАН» РАДИОСЫ** рәсми кушымталары аша тыңлагыз. Моның өчен түбәндәге QR-код аша үтегез яки App Store (iPhone өчен) һәм Google Play Market (Android өчен) платформаларыннан «Азан радиосы» кушымтасын йөкләп алыгыз.

**ANDROID ӨЧЕН:**

**IPHONE ӨЧЕН:**

| САЙТ: | ИНСТАГРАМ: | ВКОНТАКТЕ: | ТЕЛЕГРАМ-КАНАЛ: | ПОЧТА: | ТЕЛЕФОН: |
|---|---|---|---|---|---|
| azan.fm | azan.fm | azanfm | azanfm | radio@azan.fm | 8 (843) 598-09-43 |

### ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ

- **0:00** Коръәни Кәрим 0+
- **6:05** Коръән тәфсире 12+
- **6:25** Көндәлек догалар 6+
- **6:30** Тынычлык тәгълимате 12+
- **7:05** Таян Аллаһка 6+
- **7:20** Хәзрәткә сорау 12+
- **7:30** Иман тәме 12+
- **7:50** Миллият сүзлеге 6+
- **7:55** Гыйбрәтле кыйссалар 6+
- **8:05** Бәхет тулы йорт 12+
- **8:30** Күңелдән күңелгә 12+
- **8:50** Шәхесләргә шәрехләр 6+
- **9:00** Рухи хәзинә 6+
- **9:15** Гыйбадәте Исламия 6+
- **9:30** Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
- **9:40** Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
- **10:40** Миллият сүзлеге 6+
- **10:45** Көндәлек догалар 6+
- **10:50** Һәр яхшы сүз – сәдака 6+
- **11:00** 40 хәдис 6+
- **11:20** Аллаһның 99 исеме 6+
- **11:30** Мәчетләребез тарихы 6+
- **11:40** 101 вәгазь 12+
- **12:00** Өйләгә азан 0+
- **12:10** Гыйбадәте Исламия 6+
- **12:25** Миллият сүзлеге 6+
- **12:30** Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә 12+
- **14:00** Гыйбадәттә сәгадәт 12+
- **14:10** Әхлак баскычлары 6+
- **14:30** Пәйгамбәрләр тарихы 12+
- **14:45** Сөннәт юлы 12+
- **15:05** Коръән тәфсире 12+
- **15:25** Көндәлек догалар 6+
- **15:45** Бәхет тулы йорт 12+
- **16:05** Миллият сүзлеге 6+
- **16:10** Гыйбрәтле кыйссалар 6+
- **16:20** 101 вәгазь 12+
- **16:40** Күңелдән күңелгә 12+
- **17:00** Шәхесләргә шәрехләр 6+
- **17:10** Гыйбадәте Исламия 6+
- **17:30** Һәр яхшы сүз – сәдака 6+
- **17:40** 40 хәдис 6+
- **19:30** Әдәбият күрке әдәп 6+
- **19:45** Миллият сүзлеге 6+
- **20:00** Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
- **20:20** Һәр яхшы сүз – сәдака 6+
- **20:30** Нәниләргә нәсыйхәт 6+
- **20:35** Пәйгамбәрләр тарихы 12+
- **20:50** Көндәлек догалар 6+
- **21:10** Мәчетләребез тарихы 6+
- **21:30** Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
- **21:50** Хәзрәткә сорау 12+
- **22:00** Гыйбадәттә сәгадәт 12+
- **22:10** Әхлак баскычлары 6+
- **22:37** Миллият сүзлеге 6+
- **22:45** Аллаһның 99 исеме 6+
- **23:00** Коръәни Кәрим 0+

### ҖОМГА

- **0:00** Коръәни Кәрим 0+
- **6:00** Җомга тәбриге 12+
- **6:05** Коръән тәфсире 12+
- **6:25** Көндәлек догалар 6+
- **6:30** Тынычлык тәгълимате 12+
- **7:05** Таян Аллаһка 6+
- **7:20** Хәзрәткә сорау 12+
- **7:30** Иман тәме 12+
- **7:50** Миллият сүзлеге 6+
- **7:55** Гыйбрәтле кыйссалар 6+
- **8:05** Бәхет тулы йорт 12+
- **8:25** Җомга тәбриге 12+
- **8:30** Күңелдән күңелгә 12+
- **8:50** Шәхесләргә шәрехләр 6+
- **9:00** Рухи хәзинә 6+
- **9:15** Гыйбадәте Исламия 6+
- **9:30** Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
- **9:40** Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
- **10:00** Җомга тәбриге 12+
- **10:40** Миллият сүзлеге 6+
- **10:45** Көндәлек догалар 6+
- **10:50** Һәр яхшы сүз – сәдака 6+
- **11:00** 40 хәдис 6+
- **11:20** Аллаһның 99 исеме 6+
- **11:30** Мәчетләребез тарихы 6+
- **11:40** 101 вәгазь 12+
- **12:00** Өйләгә азан 0+
- **12:10** Гыйбадәте Исламия 6+
- **12:25** Миллият сүзлеге 6+
- **12:30** Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә 12+
- **14:00** Гыйбадәттә сәгадәт 12+
- **14:10** Әхлак баскычлары 6+
- **14:30** Пәйгамбәрләр тарихы 12+
- **14:45** Сөннәт юлы 12+
- **15:00** Җомга тәбриге 12+
- **15:05** Коръән тәфсире 12+
- **15:25** Көндәлек догалар 6+
- **15:45** Бәхет тулы йорт 12+
- **16:05** Миллият сүзлеге 6+
- **16:10** Гыйбрәтле кыйссалар 6+
- **16:20** 101 вәгазь 12+
- **16:40** Күңелдән күңелгә 12+
- **17:00** Шәхесләргә шәрехләр 6+
- **17:10** Гыйбадәте Исламия 6+
- **17:30** Һәр яхшы сүз – сәдака 6+
- **17:40** 40 хәдис 6+
- **19:30** Әдәбият күрке әдәп 12+
- **19:45** Миллият сүзлеге 6+
- **20:00** Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
- **20:20** Һәр яхшы сүз – сәдака 6+
- **20:30** Нәниләргә нәсыйхәт 6+
- **20:35** Пәйгамбәрләр тарихы 12+
- **20:50** Көндәлек догалар 6+
- **21:10** Мәчетләребез тарихы 6+
- **21:30** Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
- **21:50** Хәзрәткә сорау 12+
- **22:00** Гыйбадәттә сәгадәт 12+
- **22:10** Әхлак баскычлары 6+
- **22:37** Миллият сүзлеге 6+
- **22:45** Аллаһның 99 исеме 6+
- **23:00** Коръәни Кәрим 0+

### ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ

- **0:00** Коръәни Кәрим 0+
- **6:05** Коръән тәфсире 12+
- **6:25** Көндәлек догалар 6+
- **6:30** Тынычлык тәгълимате 12+
- **7:05** Таян Аллаһка 6+
- **7:20** Хәзрәткә сорау 12+
- **7:30** Иман тәме 12+
- **7:50** Миллият сүзлеге 6+
- **7:55** Гыйбрәтле кыйссалар 6+
- **8:05** Бәхет тулы йорт 12+
- **8:30** Күңелдән күңелгә 12+
- **8:50** Шәхесләргә шәрехләр 6+
- **9:00** Рухи хәзинә 6+
- **9:15** Гыйбадәте Исламия 6+
- **9:30** Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
- **9:40** Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
- **10:40** Миллият сүзлеге 6+
- **10:45** Көндәлек догалар 6+
- **10:50** Һәр яхшы сүз – сәдака 6+
- **11:00** 40 хәдис 6+
- **11:20** Аллаһның 99 исеме 6+
- **11:30** Мәчетләребез тарихы 6+
- **11:40** 101 вәгазь 12+
- **12:00** Өйләгә азан 0+
- **12:10** Гыйбадәте Исламия 6+
- **12:25** Миллият сүзлеге 6+
- **12:30** Кәлам Шәриф. Тәрҗемә 12+
- **14:00** Гыйбадәттә сәгадәт 6+
- **14:10** Әхлак баскычлары 6+
- **14:30** Пәйгамбәрләр тарихы 12+
- **14:45** Сөннәт юлы 12+
- **15:05** Коръән тәфсире 12+
- **15:25** Көндәлек догалар 6+
- **15:45** Бәхет тулы йорт 12+
- **16:05** Миллият сүзлеге 6+
- **16:10** Гыйбрәтле кыйссалар 6+
- **16:20** 101 вәгазь 12+
- **16:40** Күңелдән күңелгә 12+
- **17:00** Шәхесләргә шәрехләр 6+
- **17:10** Гыйбадәте Исламия 6+
- **17:30** Һәр яхшы сүз – сәдака 6+
- **17:40** 40 хәдис 6+
- **19:30** Әдәбият күрке әдәп 12+
- **19:45** Миллият сүзлеге 6+
- **20:00** Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+
- **20:20** Һәр яхшы сүз – сәдака 6+
- **20:30** Нәниләргә нәсыйхәт 6+
- **20:35** Пәйгамбәрләр тарихы 12+
- **20:50** Көндәлек догалар 6+
- **21:10** Мәчетләребез тарихы 6+
- **21:30** Әбү Хәнифә (р.г.) 12+
- **21:50** Хәзрәткә сорау 12+
- **22:00** Гыйбадәттә сәгадәт 12+
- **22.10** Әхлак баскычлары 6+
- **22:37** Миллият сүзлеге 6+
- **22:45** Аллаһның 99 исеме 6+
- **23:00** Коръәни Кәрим 0+

*** Тапшырулар арасында эфирда кыска хәдисләр, нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырый**


# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;

ТР МДНнең Шәригать булеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Хәләфетдинова Л. Г., Юлдашева А. И.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Шәйхетдинов А. Х.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ №2726.
График буенча – 21 нче февраль 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 140, 40 сум.
Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 22 нче февраль көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## МАРТ 2022 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрә укыла | | | | | | |
| 01 | Сиш | 04:32 | 05:05 | 06:35 | 11:55 | 12:00 | 15:20 | 17:17 | 18:59 |
| 02 | Чәрш | 04:29 | 05:02 | 06:32 | 11:55 | 12:00 | 15:22 | 17:19 | 19:01 |
| 03 | Пәнҗ | 04:27 | 05:00 | 06:30 | 11:55 | 12:00 | 15:23 | 17:21 | 19:03 |
| 04 | Җом | 04:24 | 04:57 | 06:27 | 11:55 | 12:00 | 15:25 | 17:23 | 19:05 |
| 05 | Шим | 04:22 | 04:54 | 06:24 | 11:55 | 12:00 | 15:27 | 17:26 | 19:07 |
| 06 | Якш | 04:19 | 04:52 | 06:22 | 11:54 | 12:00 | 15:29 | 17:28 | 19:09 |
| 07 | Дүш | 04:16 | 04:49 | 06:19 | 11:54 | 12:00 | 15:31 | 17:30 | 19:11 |
| 08 | Сиш | 04:14 | 04:47 | 06:17 | 11:54 | 12:00 | 15:32 | 17:32 | 19:13 |
| 09 | Чәрш | 04:11 | 04:44 | 06:14 | 11:54 | 12:00 | 15:34 | 17:34 | 19:15 |
| 10 | Пәнҗ | 04:08 | 04:42 | 06:12 | 11:53 | 12:00 | 15:36 | 17:36 | 19:18 |
| 11 | Җом | 04:05 | 04:39 | 06:09 | 11:53 | 12:00 | 15:38 | 17:38 | 19:20 |
| 12 | Шим | 04:03 | 04:37 | 06:07 | 11:53 | 12:00 | 15:39 | 17:40 | 19:22 |
| 13 | Якш | 04:00 | 04:34 | 06:04 | 11:53 | 12:00 | 15:41 | 17:42 | 19:24 |
| 14 | Дүш | 03:57 | 04:31 | 06:01 | 11:52 | 12:00 | 15:43 | 17:44 | 19:26 |
| 15 | Сиш | 03:54 | 04:29 | 05:59 | 11:52 | 12:00 | 15:45 | 17:46 | 19:29 |
| 16 | Чәрш | 03:51 | 04:26 | 05:56 | 11:52 | 12:00 | 15:46 | 17:48 | 19:31 |
| 17 | Пәнҗ | 03:48 | 04:24 | 05:54 | 11:51 | 12:00 | 15:48 | 17:50 | 19:33 |
| 18 | Җом | 03:45 | 04:21 | 05:51 | 11:51 | 12:00 | 15:49 | 17:52 | 19:36 |
| 19 | Шим | 03:42 | 04:18 | 05:48 | 11:51 | 12:00 | 15:51 | 17:54 | 19:38 |
| 20 | Якш | 03:39 | 04:16 | 05:46 | 11:51 | 12:00 | 15:53 | 17:56 | 19:40 |
| 21 | Дүш | 03:36 | 04:13 | 05:43 | 11:50 | 12:00 | 15:54 | 17:58 | 19:42 |
| 22 | Сиш | 03:33 | 04:10 | 05:40 | 11:50 | 12:00 | 15:56 | 18:01 | 19:45 |
| 23 | Чәрш | 03:30 | 04:08 | 05:38 | 11:50 | 12:00 | 15:58 | 18:03 | 19:47 |
| 24 | Пәнҗ | 03:27 | 04:05 | 05:35 | 11:49 | 12:00 | 15:59 | 18:05 | 19:50 |
| 25 | Җом | 03:23 | 04:03 | 05:33 | 11:49 | 12:00 | 16:01 | 18:07 | 19:52 |
| 26 | Шим | 03:20 | 04:00 | 05:30 | 11:49 | 12:00 | 16:02 | 18:09 | 19:54 |
| 27 | Якш | 03:17 | 03:57 | 05:27 | 11:48 | 12:00 | 16:04 | 18:11 | 19:57 |
| 28 | Дүш | 03:14 | 03:55 | 05:25 | 11:48 | 12:00 | 16:05 | 18:13 | 19:59 |
| 29 | Сиш | 03:10 | 03:52 | 05:22 | 11:48 | 12:00 | 16:07 | 18:15 | 20:02 |
| 30 | Чәрш | 03:07 | 03:50 | 05:20 | 11:48 | 12:00 | 16:08 | 18:17 | 20:04 |
| 31 | Пәнҗ | 03:04 | 03:47 | 05:17 | 11:47 | 12:00 | 16:10 | 18:19 | 20:07 |

17 март – 14 шәгъбан – Бәраәт кичәсе